**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 октябрь № 815

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы гражданнары, дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары электрон хезмәттәшлеге турында» 2012 ел, 10 август, 676 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы гражданнары, дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары электрон хезмәттәшлеге турында» 2012 ел, 10 август, 676 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 29 июль, 528 нче; 2013 ел, 5 август, 548 нче; 2014 ел, 15 март, 156 нчы; 2014 ел, 29 ноябрь, 929 нчы; 2015 ел, 30 апрель, 308 нче; 2015 ел, 2 сентябрь, 632 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы гражданнары, дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары электрон хезмәттәшлеге турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.2. Файдаланучыга җибәрелә торган хәбәрнамә үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга тиеш:

«Халык контроле» системасы хәбәрнамәләре категорияләре исемлегенә туры килгән хәбәрнамә категориясе;

Файдаланучы турында белешмә (Файдаланучы исеме яки тәхәллүсе);

хәбәрнамә юллана торган объект урнашкан урын;

проблеманың булуына дәлил сыйфатында фотофиксацияләнгән объектлар материаллары;

280 билгедән артмаган күләмдә Файдаланучының текстлы комментарие;

«Торак-коммуналь хезмәтләр» хәбәрнамәләре категориясе өчен – торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен акча күчерү һәм түләү өчен фатирны вакытлыча файдалануга алып торучыга бирелгән шәхси счет номеры; Файдаланучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;

«Экстремистлык, дини һәм милли җирлектәге низаглар» хәбәрнамәләре категорияләре өчен – текстлы комментарий, экстремистлык билгеләре булган материаллар турында хәбәр ителгән очракларда – «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле ресурсларга яки басма матбугат атамасына сылтама.»;

3.1.3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.1.2 нче пунктында каралган мәгълүматка өстәмә рәвештә Файдаланучыга җибәрелә торган хәбәрнамә үз эченә түбәндәгеләрне алырга мөмкин:

хәбәрнамәләрне карап тикшерү дәрәҗәсе (республика һәм/яки муниципаль);

хәбәрнамә авторының шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы.»;

әлеге карар белән расланган «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы юнәлешләре, хәбәрнамәләре категорияләре атамалары һәм категорияләре модераторлары исемлеген яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\815.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2012 ел, 10 август, 676 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 30 октябрь, 815 нче
карары редакциясендә)

«Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы
юнәлешләре, хәбәрнамәләре категорияләре атамалары
һәм категорияләре модераторлары исемлеге

| Т/с | Юнәлеш | Категория атамасы | Категория модераторы | Категориянең кыскача тасвирламасы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Торак-коммуналь хезмәтләр | торак-коммуналь хезмәтләр | Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе | йорт һәм аның инженер системалары (җылылык белән тәэмин итү, салкын һәм җылы су белән тәэмин итү, су агызу, электр белән тәэмин итү, газ белән тәэмин итү) торышын контрольдә тоту һәм килеп чыга торган ватылуларны бетерү, шулай ук подъездларны карап тотуны, йортка агымдагы ремонт ясауны, йорт яны территориясен чистартуны һәм башка торак хезмәтләрен күрсәтүне контрольдә тоту, идарә итүче компанияләр, торак |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | милекчеләре ширкәтләре һәм торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан сыйфатсыз күрсәтелгән коммуналь хезмәтләргә (җылылык белән тәэмин итү, салкын һәм җылы су белән тәэмин итү, су агызу, электр белән тәэмин итү, газ белән тәэмин итү) шикаятьләр. Үтәүчеләр – идарә итүче компанияләр, торак милекчеләре ширкәтләре һәм торак-төзелеш кооперативлары |
| 2. | Элемтә | мобиль элемтә | Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы | мобиль элемтә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре (алга таба – «Интернет» челтәре) хезмәтләрен сыйфатсыз күрсәтү |
| | | стационар элемтә | | теле- һәм радиотапшырулар, стационар элемтә һәм «Интернет» челтәре хезмәтләрен сыйфатсыз күрсәтү |
| | | почта | | почта элемтәсе хезмәтләрен сыйфатсыз күрсәтү (почта юлламаларын китерү вакытын сакламау, аларны югалту һәм башка проблемалар) |
| 3. | Социаль тармак | балалар бакчалары | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | балаларның балалар бакчаларында булуын оештыру, туклануны һәм белем бирү процессын оештыру мәсьәләләре |
| | | поликлиникалар һәм хастаханәләр | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министр- | сәламәтлек саклау учреждениеләре эшчәнлегендә проблемалар |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | лыгы | |
| | | уңайлы мохит | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен булган чикләүләр һәм алар өчен уңайлы мохит оештыру буенча тәкъдимнәр |
| | | социаль хезмәт күрсәтү | | гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруда проблемалар |
| 4. | Бизнес | җәмәгать туклануы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | һәркем файдалана алырлык челтәр предприятиеләре (рестораннар, барлар, кафе, кабымханәләр) тарафыннан туклану хезмәтләрен оештыруда проблемалар |
| | | сәүдә кагыйдәләрен бозу | | азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар белән сәүдә итүне оештыруда проблемалар |
| | | тышкы реклама | Федераль антимонополия хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) | гамәлдәге законнарны бозып, тышкы реклама урнаштыру фактларын ачыклау, рекламада бастырылган мәгълүмат белән гражданнарны һәм юридик затларны ялгыштыру |
| | | этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне законсыз рәвештә житештерү һәм (яки) аларның әйләнеше (ваклап сатудан гайре) | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне законсыз рәвештә житештерү һәм (яки) аларның әйләнеше (ваклап сатудан гайре) |
| 5. | Экология | чүплекләр | Татарстан Республикасы | җирләрне файдалану һәм саклау (туфракны пычрату, санкцияләнмәгән чүплекләр һ.б.) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | су | Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы | суны файдалану һәм саклау (елга акваторияләрен, сулыкларны һәм бүтән территорияләрне пычрату) |
| | | һава | | атмосфера һавасын пычрату турында мәгълүмат бирү |
| | | санитар хәле | | йортларның һәм территорияләрнең тиеш булмаган санитар хәлен ачыклау |
| | | законсыз карьерлар | | файдалы казылмаларны санкцияләнмәгән чыгару фактлары турында мәгълүмат бирү |
| 6. | Исемнәрдә һәм язуларда хаталар | исемнәрдә һәм язуларда хаталар | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты | дәүләт учреждениеләре, унитар предприятиеләр һәм башка дәүләт объектлары исемнәрендә грамматик хаталарны табу, шулай ук Татарстан Республикасы халыклары телләре турында законнарны үтәмәү фактларын ачыклау |
| 7. | Законсыз комарлы уеннар | законсыз комарлы уеннар | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | яшерен казино һәм бүтән законсыз комарлы уеннар оештыру урыннарын ачыклау |
| 8. | Төзекләндерү һәм инфраструктура | хуҗасыз хайваннар | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе | Татарстан Республикасы торак пунктлары территориясендә хуҗасыз хайваннарны (этләр һәм мәчеләр) табу |
| | | территорияне төзекләндерү | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | ишегалларын һәм йорт яны территорияләрен төзекләндерүне оештыру буенча тәкъдимнәр |
| | | капиталь ремонт | | капитальремонтны сыйфатсыз үткәрү |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 9. | Автомобильләр | үтәргә һәм/яки транспортта үтәргә комачаулый торган, юлдан читтәге автомобильләр | | йорт яны территорияләрендә махсус техника һәм/яки авария-коткару хезмәтләренә үтәргә һәм/яки транспортта үтәргә комачаулый торган һәм яшел зонага (газоннарга) куелган автомобильләр; комплектлары сүтеп алынган автомобильләрне юлдан читтә кую |
| | | җәмәгать транспорты | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | җәмәгать транспорты йөртүчеләре һәм машинистлары тарафыннан пассажирлар йөртү нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәмәү хакында, шулай ук җәмәгать транспорты паркы торышы мәсьәләләре; стационар объектлар (вокзаллар, автостанцияләр) эше турында мәгълүмат бирү |
| 10. | Юллар | юл хәрәкәтен оештыру | | юлларда юл билгеләре һәм тамгалары булу/булмау; светофорларның урнашуы һәм эшләве |
| | | федераль һәм республика юлларын карап тоту һәм ремонтлау | | федераль һәм республика юлларында юл япмасының канәгатьләнерлек булмавы |
| | | муниципаль юлларны карап тоту һәм ремонтлау | | юлларда һәм ишегалларында юл япмасының канәгатьләнерлек булмавы |
| 11. | Авыл хуҗалыгы | авыл хуҗалыгы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | авыл хуҗалыгындагы проблемалар һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 12. | Экстремистлык, дини һәм милли җирлектәге низаглар | экстремистлык, дини һәм милли җирлектәге низаглар | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | экстремистлык күренешләренә, шул исәптән «Интернет» челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында, дини һәм милли җирлектәге низаглы хәлләргә бәйле булган, шулай ук мигрантларга, чит ил дәүләтләре гражданнарына мөнәсәбәттә проблемалар |
| 13. | Хезмәтне саклау | хезмәтне саклау таләпләрен бозу | Татарстан Республикасында дәүләт хезмәт инспекциясе | хезмәткәрләрнең гомере һәм сәламәтлеге өчен куркыныч тудыручы эш урыннарында куркынычсыз хезмәт шартларын оештыру мәсьәләләре |
| 14. | «Соры» хезмәт базары | хезмәт өчен түләүнең яшерен формалары | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | хезмәткәрләргә «соры» хезмәт хакы түләү |
| | | хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштермәү | | хезмәткәрләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштерү өлкәсендә бозулар |
| 15. | Коррупциягә каршы тору | торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә коррупция | Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе | торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә коррупциячел гамәлләр |
| | | мәгълүматлаштыру өлкәсендә коррупция | Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы | мәгълүматлаштыру өлкәсендә коррупциячел гамәлләр |
| | | мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә коррупция | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән | мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында коррупциячел гамәлләр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | гомуми белем бирү өлкәсендә коррупция | министрлыгы | гомуми белем бирү оешмаларында коррупциячел гамәлләр |
| | | югары белем бирү өлкәсендә коррупция | | югары белем бирүче мәгариф оешмаларында коррупциячел гамәлләр |
| | | сәламәтлек саклау өлкәсендә коррупция | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | медицина оешмалары эшчәнлегендә коррупциячел гамәлләр |
| | | социаль өлкәдә коррупция | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | социаль өлкә учреждениеләре эшчән-легендә коррупциячел гамәлләр |
| | | сәнәгать өлкәсендә коррупция | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | сәнәгать өлкәсендә коррупциячел гамәлләр |
| | | сәүдә өлкәсендә коррупция | | сәүдә өлкәсендә коррупциячел гамәлләр |
| | | экология өлкәсендә коррупция | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы | экология өлкәсендә коррупциячел гамәлләр |
| | | территорияләрне төзекләндерү өлкәсендә коррупция | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | территорияләрне төзекләндерү өлкәсендә коррупциячел гамәлләр |
| | | капиталь ремонтлау өлкәсендә коррупция | | капиталь ремонтлау өлкәсендә коррупциячел гамәлләр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | авыл хуҗалыгы өлкәсендә коррупция | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | авыл хуҗалыгы өлкәсендә коррупциячел гамәлләр |
| | | эшкуарлык өлкәсендә коррупция | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | эшкуарлык өлкәсендә коррупциячел гамәлләр |
| | | җир кишәрлекләре белән эш итүгә вәкаләтле җирле үзидарә органнарына шикаятьләр буенча җир белән алыш-бирешләр өлкәсендә коррупция | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министр-лыгы | җир белән алыш-бирешләр өлкәсендә коррупциячел гамәлләр |
| | | дәүләт сатып алу-лары өлкәсендә кор-рупция | Сатып алулар буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты | дәүләт сатып алулары өлкәсендә коррупциячел гамәлләр |
| | | транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә коррупция | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә коррупциячел гамәлләр |
| 16. | Куркынычсыз-лык | янгын куркынычсыз-лыгы кагыйдәләрен бозу | Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы | янгын куркынычсызлыгы таләпләре бозылган биналар һәм урыннар булу |
| 17. | Спорт | спорт объектлары эшчәнлеге | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы | спорт объектлары эшчәнлеге |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 18. | Мәдәният | мәдәният учреждениеләре эшчәнлеге | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | мәдәният учреждениеләре эшчәнлеге |
| | | мәдәният һәйкәлләре | | мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә бозулар |

F:\KARAR\2015\815.doc